ГЛАВА ШЕЛАНГОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Советская, д.7, с. Шеланга,
422577

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ШИЛАНГЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Совет ур., 7 нче йорт, Шилангы авылы,
422577

Тел.: (84379) 32-7-48, факс: (84379) 32-7-02.

29.11.2024 ел, № 14

На №_______________от________________

КАРАР

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының
Шилангы авыл җирлеге Шилангы торак пункты территориясенең бер өлешендә
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлегенең Шилангы авылы территориясенең бер өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?" дигән сорау буенча 2024 елның 29 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде:

- Шилангы торак пункты Куйбышев урамы буенча электр элемтәсен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка торак пунктларны, трансформатор һәм башка подстанцияләрне, бүлү пунктларын һәм башка мәйданчыкларны тышкы яктырту челтәрләрен реконструкцияләү, урамнарда яктыртуны ремонтлау

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 20 граждан, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 12 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен - гражданнар җыенының 12 катнашучысы тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен - җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлеге Шилангы авылы территориясенең бер өлешендәге гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. «Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлегенең Шилангы авылы территориясенең бер өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган, авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән билгеләнгән ташламалы категориядәге гражданнардан тыш, һәр кешедән 2025 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле

әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы? - Шилангы торак пункты Куйбышев урамы буенча электр элемтәсен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка торак пунктларны, трансформатор һәм башка подстанцияләрне, бүлү пунктларын һәм башка мәйданчыкларны тышкы яктырту челтәрләрен реконструкцияләү, урамнарда яктыртуны ремонтлау дигән сорау буенча караны таныrга.

3. Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авылы җирлеге территориясенең бер өлешендә гражданнар җыены нәтиҗәләрен Шилангы авыл җирлеге мәгълүмат стендларында игълан итәргә

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: В. В. Майоров